Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

**КАРАР №4**

Шумково авылы 2024 елның 12 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Башлыгы урынбасарын сайлау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 маддәсенә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 маддәсенә,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Шумково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 33, 45 нче маддәләренә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Башлыгы урынбасары итеп бер мандатлы 2 нче сайлау округы буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге депутаты Моталлапов Нурислам Нурмыхәммәт улын сайларга.
2. Карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Шумково авылы, Үзәк урам, 4 йорт; Олы Укмас авылы, Үзәк урам, 42 йорт; Хутор авылы, Яшьлек урамы, 5 йорт; Әшнәк-Качкалак авылы, Югарыгы урам, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы утырышында
рәисле китүче, иң өлкән депутат ____________ Абрашенкова Л.Ф.